| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ МАЛОМЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 05 июль Кече Мәми авылы №9

Татарстан Республикасы Кече Мәми авыл җирлеге
башкарма комитетының 2015 елның 25 февралендәге
5 нче номерлы « Кече Мәми авыл җирлегенең
муниципаль милкендә булган барлык биналар,
ялланган йорт белән идарә итү тәртибе турындагы
нигезләмәне раслау хакында»гы карарын
гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кече Мәми авыл җирлеге башкарма комитетының-2015 елның 25 нче февралендәге 5 нче номерлы « Кече Мәми авыл җирлегенең муниципаль милкендә булган барлык биналар, ялланган йорт белән идарә итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарын (2019 елның 21 нче мае № 8 үзгәрешләр белән) гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, http://pravo.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Кече Мәми авыл
җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Е.Н.Алексеева